**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

30.12.2021 1498-п

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Ык елгасы, Камышлы елгасы, Минзәлә елгасы, исемсез агымсу (Ташлы ерымында Мишә елгасының уң кушылдыгы) – 1 кишәрлек су объектларының су саклау зоналарын һәм яр буе саклык полосаларын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә Ык елгасының (чыганактан 227,71-231,94 км кишәрлектә), Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә Ык елгасының (чыганактан 179,62-185,73 км кишәрлектә), Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы территориясендә Камышлы елгасының (чыганактан 3,875-4,560 км кишәрлектә), Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы территориясендә Минзәлә елгасының (чыганактан 82,49-84,12 км кишәрлектә), исемсез агымсуның (Ташлы ермагында Мишә елгасының уң як кушылдыгы) – Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендәге 1 кишәрлекнең (чыганактан 9,98-10,68 км кишәрлектә) яр сызыгы өлешенең (су объектының чикләренең) урнашу урынын җентекләү эшләре уздырылуга бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 10 гыйнварындагы 17 номерлы карары белән расланган Су объектларының су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе саклык сызыклары чикләрен билгеләү кагыйдәләре, Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясы, «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары нигезендә һәм су объектларының су саклау зоналары чикләре һәм яр буе саклык сызыклары чикләре турындагы белешмәләрне дәүләт су реестрына һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү максатларында башкарылган эш йомгаклары буенча

**боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларының су саклау зоналары һәм яр буе саклык сызыклары киңлеген Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясы нигезендә әлеге чикләрдә хуҗалык һәм башка төр

эшчәнлекне гамәлгә ашыруның махсус режимын исәпкә алып билгеләргә:

1.1. Ык елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 200 м;
яр буе саклык сызыгының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м, ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м, капма-каршы яисә нульле авышлык булганда – 30 м.

1.2. Камышлы елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык сызыгының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м, ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м.

1.3. Минзәлә елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 200 м;
яр буе саклык сызыгының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м, ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м, капма-каршы яисә нульле авышлык булганда – 30 м.

1.4. Исемсез агымсу (Ташлы ермагында Мишә елгасының уң як кушылдыгы) - 1 кишәрлек:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык сызыгының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м, ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м.

2. Су объектларын саклау бүлегенә (В.А.Долгов):

2.1. Билгеләнгән тәртиптә дәүләт су реестрына кертү өчен, материалларны Су ресурслары федераль агентлыгына җибәрергә.

2.2. Белешмәләрне билгеләнгән тәртиптә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен, материалларны Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

2.3. Белешмәләрне су саклау зоналары һәм яр буе саклык сызыклары чикләре үз территорияләренә карата билгеләнә торган муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына җибәрергә.

3. Экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендәге проектларны пропагандалау бүлегенә (Е.В.Веселова) әлеге боерыкны татар теленә тәрҗемә итүне тәэмин итәргә.

4. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.И.Ткачук) әлеге боерыкны теркәү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары О.В.Манидичевка йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков